Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге Советының утыз өченче утырышы

Надеждино авыл җирлеге Советы

**КАРАРЫ**

19 апрель, 2024 ел № 86

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Надеждино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советының 2022 елның 29 апрелендәге 39 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Надеждино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәгә (Советның 2023 елның 31 мартындагы 60 номерлы, 2023 елның 30 октябрендәге 74 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 78 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 8 статьяның 4 өлешендәге 11 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11.2 пунктча өстәргә:

«11.2.) «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең интеграцияләнгән мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр, аларга федераль бюджет акчалары (дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) капиталь кертемнәрне финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы төзи;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге башлыгы И.З. Галәветдинов